СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

---

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**28 июль 2026 ел** **№33**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының « Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының « Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында" Арча район Советының 2026 елның 9 февралендәге 30 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге халкының фикерен белдереп, "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән үзгәртү турында Арча район Советы инициативасын хупларга, кушымтада бирелгән карта-схема нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Иске Кырлай авыл җирлегенең рәсми стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2 йорт; ТР, Арча районы, Иске Кырлай авылы, Үзәк урам, 12а йорт.


3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

*Арча муниципаль районы*
*Иске Кырлай авыл җирлеге*
*Советы карарына кушымта*
*“28” июль 2026 № 33*

## Карта-схема
границ муниципальных образований
с учетом изменений




Условные обозначения

- граница Арского муниципального района
- границы муниципальных образований
- А-Б - смежная граница муниципального образования «город Арск» и Старокырлайского сельского поселения
- административные центры поселений
- населенные пункты
- территория Старокырлайского сельского поселения Арского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования «город Арск» Арского муниципального района